Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
## УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 25 (76)

1 сентябрь 2013 ел

*Өч наданга алмашынмас бер язу белгән кеше,*
*Мәгърифәт эстәр, иренмәс һич кеше булган кеше.*

Габдулла Тукай



www.kpfu.ru

чыгарылышның тулы мультимедиа-version

UNIVERSMOTRI.RU

## Хөрмәтле беренче курс студентлары!

Сезне тормышыгыздагы мөһим һәм әһәмиятле вакыйга – Казан федераль университетына укырга керүегез белән тәбрик итәм.

Сез 2014 елда 210 яшен тутырачак, Россиядә иң борынгы уку йортларының берсе булган университетның бусагасын атлап кердегез. Ике гасырдан артык тарихы булган уку йорты 110 меңләп кешене дипломлы белгеч итте, аларның күбесе төрле өлкәдә: фән, мәдәният, дәүләт идарәсе, хуҗалык-оештыру эшләрендә зур үрләр яулады. Федераль уку йорты дәрәҗәсен алгач, университет студентларны, заманча белем бирү белән беррәттән, реаль икътисад, IT-тармак, банк эшчәнлеге, идарә итү өлкәсендә өстәмә күнекмәләр һәм белемнәр белән дә тәэмин итә.

Безнең университет структуралары ватаныбыз һәм чит ил партнерлары белән тыгыз бәйләнештә булган эре фәнни-белем бирү холдингына әйләнде. Хезмәттәшлек, академик өлкә белән беррәттән, уртак кафедралар, лабораторияләр, җитештерү үзәкләре, кече инновацион предприятиеләр кысаларында, шул ук вакытта икътисадның реаль секторында да алып барыла.

Университетта укыту яңа педагогик һәи инженерлык белеме бирү модельләре буенча гамәлгә ашырыла. Әлеге юнәлешләр буенча әзерлек профильле институт һәм факультетлар базасында алып барыла. Шуның белән бергә, педагоглар әзерләү безнең Алабуга филиалында да башкарыла, ә Яр Чаллы филиалында (аның нигезен Кама инженер-икътисади академия тәшкил итте) инженер кадрларын әзерләүнең традицион системасы саклана. Шул рәвешле, хәзер без ике белем бирү моделенә нигезләнеп эшлибез һәм аларның өстенлекле якларын бәяләү мөмкинлегенә ия. Алай гына да түгел, КФУ өстәмә һөнәри белем бирү, дәүләт һәм муниципаль эшчеләренең, ТРның белем бирү өлкәсендә хезмәт куючыларның квалификациясен күтәрүне дә тәэмин итә. Быелдан без җитди тикшеренү эшләре белән шөгыльләнәчәк врачлар да әзерли башлыйбыз. Алар алдынгы фәнни юнәлешләрне хастаханә практикасы белән бәйләп алып барырлар дип уйлыйбыз. Фәнни эшчәнлекнең яңа дәрәҗәсе турында да тулы ышаныч белән әйтеп була. Хәзерге вакытта КФУда фәнни тикшеренүләр 28 юнәлеш буенча алып барыла. Шуларның 13е табигый фәннәр, 10сы гумантар, 5се дисциплинаара фәннәргә туры килә. Яңа җиһазлар базасы белән тәэмин ителгән 130дан артык лаборатория ачылды һәм модернизацияләнде.



КФУның партнерлары көннән көн арта: 35 илдән 90нан артык вуз һәм фәнни үзәк. Бу исемлектә шулай ук чит ил фәнни үзәкләре дә бар (РИКЕН, Сорбонна, Нью-Йорк штаты университеты һ.б.). Университетыбыз уртак магистратура, «икеләтә диплом», «икеләтә яклау» программаларын гамәлгә ашыра. Безнең дөньякүләм масштабтагы университетлар төркемәнә керү өчен барлык мөмкинлекләребез бар һәм без аларны арттыру өстендә даими эшлибез. Моның саллы дәлиле булып КФУның конкурс нигезендә Россиянең 15 алдынгы югары уку йортлары исемлегенә керүе тора.

Сезнеңөченбикмөһим фикер җиткерәсем килә. Университетны тәмамлаганнан соң да сезгә даими рәвештә укырга, белем тупларга туры киләчәк, чөнки фән һәм мәгълүмат якынча һәр өч ел саен яңарып тора. Ул гына да түгел, хәзерге заман икътисады бернечә мәртәбә һөнәрне, эш урынын алмаштыру тенденциясен алга чыгарды. Уку йортын тәмамлаганнарның үз белгечлекләре буенча эшләмәве инде гадәти күренешкә әйләнеп бара. Шулай булгач, сез үзгәреп тора торган һәм конкурентлы икътисад шартларына җайлашырга, һәр эштә дә уңышка омтылырга һәм куйган максатларыгызга ирешә белергә тиеш. Университетыбызның физика факультетын тәмамлаган студентларның шәһәр мэрлары яисә зур компанияләрдә җитәкчебулуларын,юридик факультетта укыган кайбер студентларыбызның Россиядә һәм җөмһүриятебездә министр дәрәҗәсенә үсеп җитүләрен мисал итеп китерергә була.

Әлбәттә, студент тормышы гел уку һәм фән белән генә шөгыльләнүдән тормый. Ул шулай ук кызыклы мәдәни вакыйгаларда, махсус уздырылган конкурс-бәйрәмнәрдә катнашу да. Универсиада-2013 Казанда узсын өчен, безнең университет студентлары күп көч куйды, алар дөнья күләмендәге форумны әзерләүдә һәм үткәрүдә актив катнашты. Шул исәптән, спортчылар сыйфатында да. Сезгә Универсиададан калган мирасны үзләштерергә, аның спорт объектларын дөрес файдаланырга, волонтерлык хәрәкәтен дәвам итәргә һәм, гомумән, Казанны Россиянең башка шәһәрләре дә үрнәк алырлык актив, спорт сөючән, белемле, алдынгы карашлы яшьләр башкаласына әверелдерү өчен, үз өлешегезне кертергә туры киләчәк.

Университеттагы тормышыгызның беренче көннәреннән үк тәвәккәлләнеп эшкә керешсәгез иде, яшь дусларым! Куйган максатларыгызга омтылыгыз һәм сез барысына да ирешәчәксез. Мин, үз чиратымда, сезгә укуда, спортта, иҗатның төрле өлкәләрендә уңышлар һәм, иң мөһиме, тормышта лаеклы урын табуыгызны телим!

**Илшат ГАФУРОВ,**
**КФУ ректоры**

## Университет җитәкчелеге



Президент – **Сәлахов Мәкъзүм Хәлимуллович**
☎ 233-79-34,
✉ president@kpfu.ru



Уку-укыту эшләре буенча проректор - **Минзарипов Рияз Гатауллович**
☎ 233-70-03
✉ riaz.minzaripov@kpfu.ru



Фәнни эшчәнлек буенча проректор - **Нургалиев Данис Карлович**
✉ danis.nourgaliev@kpfu.ru
292-72-88



Административ эшләр буенча проректор - аппарат җитәкчесе - **Хашов Андрей Николаевич**
☎ 292-79-13
✉ a-ha1964@mail.ru




Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор - **Сафиуллин Марат Рәшитович**
☎ 233-72-77,
✉ lgudyaev@kpfu.ru



Финанс эшләре буенча проректор - **Муллакаева Рәйсә Рифовна**
☎ 233-70-71
✉ raisa.mullakaeva@kpfu.ru




Хуҗалык эшләре буенча проректор – **Сафиуллин Ленар Солтангалиевич**
☎ 233-74-06
✉ lenar.safiullin@kpfu.ru



Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор – **Межведилов Ариф Магидинович**
☎ 233-74-29, 292-72-26
✉ amezhved@mail.ru



Тышкы элемтәләр буенча проректор – **Латыйпов Линар Наилевич**
☎ 233-74-47
✉ linar.latypov@kpfu.ru



Инновацион эшчәнлек буенча проректор - **Кашапов Наил Фаикович**
☎ 233-78-71
✉ kashnail@gmail.com

## Казан федераль университеты ул:

- 24 институт һәм факультет.
- 3 югары мәктәп.
- 3 кадрларны яңадан әзерләү һәм белемнәрен арттыру үзәге.
- Якынча 50000 студент, шуларның 8000е КФУга быел кабул итеде.
- Якын һәм ерак көнчыгыштан 1000 студент, шуларның 400дән артыгы быелдан КФУда белем ала башлады.
- 7600дән артык хезмәткәр.
- 3000нән артык укытучы.
- 52000 кв. м. мәйдан алып торучы укыту-лаборатория үзәкләре.
- 13 спорт корылмасы, шуларның иң зурлары: «Мәскәү», «Бустан», «Уникс».
- 4 шәһәр читендә урнашкан лагерь.
- Җәмәгать туклану һәм сату комбинаты, медицина үзәге, матурлык салоны.

## КФУ үсешенең өстенлекле юнәлешләре:

- Нефть табу, эшкәртү һәм нефть химиясе
- Яңа җиһазлар һәм нанотехнологияләр
- Мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм инфраструктура
- Биотехнологияләр, фармацевтика һәм биомедицина
- Комплекслы социогуманитар тикшеренүләр.

# Камиллеккә чикләр юк!



Филология һәм сәнгать институты директоры **Җамалетдинов Радиф Рифкать улы**
Телефон: (843) 292-42-87.
Адрес: Казан шәһәре, Татарстан ур., 2





Әгәр син хәзерге гүзәл мизгелдә безнең газетаны тотып, анда язылганнарны укыйсың икән, бу төш түгел! Син мәгърур Казан федераль университеты студенты булгансың дигән сүз! Ә кайберләрегез, әлеге бөек уку йортының Филология һәм сәнгать институты студенты! Ә алда сине онытылмаслык студент еллары көтә.

Бүгенге көндә институт составында ике бүлек – **татар филологиясе** һәм **мәдәниятара багланышлар, рус һәм чит ил филологиясе бүлекләре, С.Сәйдәшев ис. Югары сәнгать мәктәбе** бар. Бу институт КФУның иң эре институтларының берсе булып тора. Биредә өч мең ярымнан артык студент белем ала.

Укыту программаларыннан тыш, биредә син балачактан килгән талантларыңны үстерә алачаксың. Җыр-моңга гашыйклар җырлап укыса, биергә яратучылар бии-бии остарыр. Иҗатка һәвәсләрдән чын шагыйрь-язучылар әзерләнер. Әгәр син театр сәнгате буенча да үзеңне камилләштерергә теләсәң, рәхим ит! «Мизгел» театры да яшь йолдызлар ачуын дәвам итәр. Биредә сине чын профессионаллар көтә! Укудан тыш вакытны әрәмгә уздырма, чөнки син төрле түгәрәкләрдә йөреп алган күнекмәләреңне тормышта да файдалана алачаксың. Шулай ук синең мондый осталыкларыңны университет, шәһәр, республика, хәтта ил күләмендә уза торган конкурс-фестивальләрдә дә югары бәяләрләр.

! **Онытма:** уку – ул энә белән кое казу. Син, КФУ студенты булып, үз өстенә зур җаваплылык та аласың. Беренче чиратта, үзеңнең, әти-әниеңнең, якыннарыңның йөзенә кызыллык китермәскә, икенчедән, бай тарихы, үткәне, якты бүгенгесе булган уку йортының ышанычын акларга, аның киләчәген тагын да нурлы итәргә тиеш булачаксың.



# Укымышлы ил гизәр!

Быел уку йортыбызда яңа форматта эшли башлаячак **Халыкара мөнәсәбәтләр институтына** укырга кергән кичәге мәктәп укучылары - бүген үзе зур хыял-максатларны тормышка ашыру турында уйлаучы студентлар. Тарихын белмәгәннең киләчәге юк, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Яшь буынның үткәнебез белән кызыксынуы, аны киләчәккә тапшырырга тырышуы сөендерә.

Халыкара мөнәсәбәтләр институтында **тарихны** өйрәнүгә зур игътибар биреләчәк. Тарих бүлегендә сине тарихның бөтен нечкәлекләре белән танышу, төрки халыклар, Идел һәм Урал буе, чит ил тарихын өйрәнү көтә. Халыкара мөнәсәбәтләр, көнчыгышны өйрәнү институты, тәрҗемә белеме һәм Бөтендөнья мәдәни мирас бүлекләрендә син шулай ук төпле белем һәм ныклы тәрбия алачаксың.

Сине лекцияләр тыңлау, семинарларда катнашу, контроль биремнәр башкару гына көтми, ә рәхәтләнеп чын тарихи дөньяга чумарсың. Бәлки нәкъ менә син югалган цивилизация серләрен ачарсың, борынгы кульязмаларны, укытучы булу нечкәлекләрен өйрәнерсең. Шулай ук Көнчыгыш, Азия һәм Африка илләре тарихы, икътисады, сәясәте белән танышырсың. Синең өчен лекцияләрне хәтта АКШның Индиана, Ратгерс, Огайо институтларыннан килгән профессорлар укыячак. Институт бик күп чит ил университетлары белән хезмәттәшлек итә. Димәк, син Бөекбритания, Германия, Төркия, Польша, Казахстан һәм башка илләрдә стажировка үтә яисә җәйге мәктәпләрдә белемеңне арттыра алачаксың.

Халыкара мөнәсәбәтләр бүлеген тәмамлаган белгечләр рәхәтләнеп хокук проектлары кабул итүдә, эчке сәяси курсларны тормышка ашыруда катнаша алачак. Димәк, синең алда бөтен ишекләр дә ачык. Студент елларының һәр көненнән файда алып, белем тупла, уку йорты тудырган һәр мөмкинлектән дөрес итеп файдалан.

Унышлар, дусым! Син бүген күпсанлы студентлар армиясенең бәхетле әгъзасы. Шуны онытма!



Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры **Хәйретдинов Рамил Равил улы**
Телефон: (843) 236-79-80.
Адрес: Казан шәһәре, К.Маркс ур., 2



# Белем киңлекләре



**Педагогика һәм психология институты** студенты икәнсең, бу һөнәрне гомер буе камилләштерергә әзер бул. Чөнки тора-бара биредә алган белемнәр генә җитми башлый һәм син тагын да күбрәк белергә, фәнгә бәйле нечкәлекләрне эзләргә тырышачаксың. Моңа сиңа дөрес юнәлеш, кирәкле мәгълүмат бирәчәкләр – калганы үз кулыңда!

Педагогиканы яратучылар күп гасырлардан килгән бай тәҗрибә белән танышып, алга таба үзләре мәктәп укучыларын фән серләренә төшендерә алачак.

Әгәр син психология юнәлешен сайлагансың икән, бик тиздән үз-үзең һәм әйләнә-тирә белән гармониягә керү юлларын, аерым кешеләрнең психологик үзенчәлекләрен аерып карый алачаксың.



Педагогика һәм психология институты директоры **Кәлимуллин Айдар Минимансур улы**
Телефон: (843) 292-91-23.
Адрес: Казан шәһәре, Межлаук ур., 1

Педагогика һәм психология институты Януш Корчак халыкара җәмгыяте, Кытай университетлары һ.б. белән хезмәттәшлек җепләрен ялгады һәм биредә күпсанлы халыкара семинар, конференцияләр уздырыла. Аларда син дә катнашып, яңадан-яңа ачышлар, зур уңышларга ирешә аласың.

# СтудНавигатор

**Шартлы билгеләр**

- Уку корпусы
- Филиал
- Спорт корылмалары
- Тулай торак
- Китапханә уку залы
- Актлар залы
- Ашханә, буфет
- Wi-Fi зонасы
- Банкомат
- Канцтоварлар
- Велосипед кую урыны
- Почта

## Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты

*Кремль ур., 4/5*



## Идарә иту һәм территориаль үсеш институты

## Өзлексез белем бирү институты

*Кремль ур., 6/20*



## КФУның та...

(К...

Фундаменталь медицина һәм биология институты
Юридик факультет
КФУ администрациясе
Матбугат үзәге

*КФУның төп бинасы, Кремль ур., 18*



Физика институты

*Кремль ур., 16 а*




Экол...

исем...
һәм ...
Хиса...

техно...

## Филология һәм сәнгать институты:

*Татарстан ур., 2*



## Филология һәм сәнгать институты:

*Межлаук ур., 3/45*




## Мәгълумати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе

## КФУның «Univer» Медиа-Үзәге

Газета редакцияләре:
«Казанский университет», «Darelfөnyn», Univer-TV







1. Төп бина.
2. Ректор бинасы, элек Н.И. Лобачевский яшәгән йорт (хәзер «механичка»).
3. Геометрик корпус.
4. Криоген корпус.
5. Астрономия кафедрасы.
6. Тышкы элемтәләр департаменты.
7. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә (иске бинасы), Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге.
8. Анатомик театр.
9. А.М.Бутлеров исем...
10. Казан Император ... университетының меди... лабораторияләренең э... хәзер КДМУның 3 уку...
11. Көнбатыш ярымци...
12. Атом-төш физикас...
13. Көнчыгыш ярымци...
14а. УНИКС, мәдәни ...
14б. УНИКС, спорт к...
15. Мәгълумати систем... технологияләр югары ...

## Халыкара мөнәсәбәтләр институты

## Фәлсәфә факультеты

*Пушкин ур., 1/55*



## Педагогика һәм психология институты

*Межлаук ур., 1*



## Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

*Товарищеская ур., 5*



## Халыкара мөнәсәбәтләр институты

## Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты

*Сул Болак ур., 44*



## Экология һәм география институты

*Сул Болак ур., 34*



## «Мәскәү» спорткомплексы

*Мәскәү ур., 49*



## арихи үзәге
ГУ)



А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты
*Лобачевский ур., 1/29*

огия һәм география институты
Н.И.Лобачевский мендәге Математика механика институты,
плау математикасы һәм мәгълүмати ологияләр институты,
Тел институты
*II корпус Кремль ур., 35*






ендәге НИХИ.
ицина факультеты
лекке бинасы,
корпусы.
ркуль.
сы лабораториясе.
ркуль.
комплексы.
омплексы.
малар һәм
мәктәбе

КФУның «Univer» Медиа-Үзәге
Газета редакцияләре:
«Казанский университет», «Darelfønyn»,
Univer-TV.
16. ТР Милли китапханәсе.
17. Икенче уку корпусы.
18. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә.
19. А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты.
20. Физика институты.
21. Сковородка.

## Фундаменталь медицина һәм биология институты
*К.Маркс ур., 74*



## Икътисад һәм финанс институты
*Бутлеров ур., 4*



## «Бустан» спорткомплексы,
*Кулагин ур., 8а*



«Бустан» бассейны



## Универсиада авылы



Универсиада авылы



Теннис академиясе



«Буревестник» бассейны

## Яр Чаллы институты
*Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 68/19*

**Факультетлар:**
Автоматизация һәм прогрессив технологияләр факультеты
Автомеханика
Төзелеш
Икътисад
Юридик
Чит телләр
Филология һәм журналистика
Гамәли математика һәм мәгълумати технологияләр
Гуманитар бүлек



## Алабуга институты
*Алабуга ш., Казан ур., 89*

**Факультетлар:**
Биология
Технология-икътисад
Чит телләр
Тарих һәм юриспруденция
Психология һәм педагогика
Рус филологиясе һәм журналистика
Татар һәм чагыштырма филология
Физик культура
Икътисад һәм идарә
Физика-математика



## Чистай филиалы
*Чистай ш., Студентлар ур., 15*



Гуманитар һәм социаль-икътисади фәннәр кафедрасы
«АПК икътисады» кафедрасы
«АПК механизациясе» кафедрасы
Су белән тәэмин итү һәм су алыштыру кафедрасы

## Яшел Үзән филиалы
*Яшел Үзән ш., С.Сәйдәшев ур., 4*



**Факультетлар:**
Физика-математика
Гуманитар

# Мәгълүмат үзәгендә кайна!

Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында шулай ук талантлы, актив, креатив студентлар белем ала. Сиңа күңелсезләнеп, моңсуланып утырырга вакыт калмаячак. Үзенчәлекле уку процессы тулысы белән студентларның талантларын үстерүгә, арттыруга юнәлтелгән.

Беренче курстан ук радио, телевидение яисә газета-журналларда практика үтә башлаячаксың. Андагы мохит, атмосфера, кызыклы кешеләр, артистлар белән таныша, аралаша алачаксың. Сине тиз арада мәгълүматны кабул итәргә, аны эшкәртергә һәм башкаларга җиткерергә өйрәтәчәкләр.

Газета-журналлар белән эш итәргә яратучылар да университетта һәрдаим чыгып килә торган **«Darelfөnyn»** һәм **«Казанский университет»** газеталарында үз көчләрен сынап карый алалар.

Телевидениене үз итүчеләргә дә әллә кая барып йөрисе юк: университетта бүгенге көндә заманча җиһазландырылган һәм Full HD форматындагы **«UniverTV»** телекомпаниясе эшләп килә. Тәүлекнең төрле вакытында интернетка кереп **(universmotri.ru)**, тапшыруларны карау мөмкинлеге дә бар. Һәр теләгән студент биредә үзен күрсәтә, иҗади планнарын гамәлгә ашыра ала. Син дә тәвәккәллә!

Сүз уңаеннан!

Син уку йортындагы яңалыклар һәм башка кирәкле мәгълүматлар белән **университетның рәсми сайты** аша да таныша аласың. Әгәр сиңа тиз арада университет белән бәйле телефон номеры яисә e-mail кирәк икән, Интернеттан **www.kpfu.ru** адресын җый. Биредә син КФУ турындагы иң соңгы һәм иң дөрес яңалыклардан хәбәрдар булырсың, университет тормышының үзәгендә кайнарсың.

Матбугат конференциясе, пресс-кит, медиа-план... Бу сүзләр сиңа таныш түгелме? Борчылма, син аларны Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында уку дәверендә еш ишетерсең. Ә КФУның Матбугат үзәгендә исә син алар белән гамәлдә таныша аласың. Матбугат үзәге хезмәткәрләре шәһәр, республика газеталары битләрендә, телевизор экраннары, Интернет челтәре аша университет абруен күтәрү юнәлешендә эшли. Биредә сине дә бик теләп кабул итәчәкләр.



Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты директоры **Мөхәрәмов Наил Мидхәт улы**
Телефон: (843) 200-09-11, 200-09-07.
Адрес: Казан шәһәре, Товарищеская ур., 5






# Хак сүз

Юридик факультетның тарихы бик еракларга – уку йортыбызның оешкан көннәренә барып тоташа. Әгәр син бу бүлек студенты булу бәхетенә ирешкәнсең икән, үзеңнең иң дәрәҗәле, бай тарихлы факультетта укуың белән горурлана аласың. Димәк, син хокук белән кызыксынасың, законнар үтәлешен тикшерергә телисең. Сизелмичә дә үтеп китәчәк студент еллары үз нәтиҗәсен озак көттермәс, чөнки югары квалификацияле белгечләргә ишекләр һәрвакыт ачык! Юрфак үзенең төрле мавыктыргыч проектлары белән дә дан тота. Әйтик, «Намуслы йөрәк» социаль проекты мөмкинлекләре чикле балаларга хокук нигезләрен өйрәтүне күз алдында тота. Әлеге факультет студентлары бик теләп гражданнарга тормышта килеп туган төрле катлаулы хәлләрне чишәргә ярдәм итә. Шулай ук «Студентлар наркотикларга каршы» конкурсы да игътибарга лаек һ.б. Чит телне яхшы белгән студентлар үзләрен Европа университетлары үткәрә торган проектларда да сынап карый һәм чит илгә стажировкага бара ала. Әлеге факультетта булган мөмкинлекләрнең чиге юк! Шуңа күрә үз хокукларыңны белеп, студент елларыңны актив үткәр!



Юридик факультет деканы **Тарханов Илдар Абдулхак улы**
Телефон: (843) 233-71-38.
Адрес: Казан шәһәре, Кремль ур. 18

# Беренче курслар өчен календарь!





**Сентябрь**
- Беренче курс студентларының университет җитәкчелеге белән очрашуы
- Студентлар тормышы буйлап экскурсия (концерт программасы)



**Октябрь**
- Беренче курслар бәйрәме
- Беренче курслар спартакиадасы
- «Сәлам, талантлар» һәм «Бер адым алга» актив мәктәбе



**Ноябрь**
- Университетның туган көне
- КФУның КВН Лигасы махсус проекты



**Декабрь**
- Ел дәвамында уздырыла торган «КФУның Ел студенты» конкурсына йомгак ясау



**Гыйнвар**
- Студентлар бәйрәме, ягъни «Татьянин день»



**Февраль**
- Сәламәтлек поезды
- Иҗат яшьләренең «Байтик» слеты
- КФУның КВН Лигасы фестивале




**Март**
- Студентлар язы
- «Точка зрения» халыкара фәнни-гамәли конференция




**Апрель**
- «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл» девизы астында уздырыла торган сәламәтлек көне



**Май**
- Җиңү бәйрәме. Уку йортыбыз ветераннарын хөрмәтләү тантанасы



**Июнь**
- Яхшы билгеләргә тәмамлаган чыгарылыш курс студентларына кызыл диплом тапшыру тантанасы




**Июль**
- Иҗат яшьләренең «Креативный бум» слеты

КФУ СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ ПРОФСОЮЗ ОЕШМАСЫНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ – СТУДЕНТЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ, ГРАЖДАНЛЫК ҺӘМ ЗАКОНЛЫ ХОКУКЛАРЫН ТӨРЛЕ ДӘРӘҖӘДӘ ЯКЛАУ. ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА УЛ ҮЗЕНӘ ПРОФСОЮЗ ӘГЪЗАСЫ БУЛЫП ТОРГАН 9 МЕҢНӘН АРТЫК СТУДЕНТНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ ҺӘМ РЕСПУБЛИКАБЫЗДАГЫ ИҢ ЭРЕ ПРОФСОЮЗ ОЕШМАЛАРЫННАН САНАЛА.




# Безнең белән бул – Профсоюзга кер!




Аннан кала әлеге оешма студентларга үз-үзләрен күрсәтү, коммуникативлык күнекмәләрен алу, лидер һәм оештыручы сәләтен тәрбияләү, үз хокукларын якларга өйрәнү мөмкинлеген дә бирә.

## Профсоюзга ничек керергә?

Моның өчен студентлар Профкомына («УНИКС» концертлар залы, 107-108 бүлмәләр) мөрәҗәгать итәргә кирәк. (Эш көннәрендә 9.00 дан 17.00гә кадәр).

## Социаль туклану

Социаль туклану сменалап оештырыла: ел саен **8 смена** (һәр смена 20 көн (семестрга – 4 смена). Мондый бушлай туклану һәр студентка смена дәвамында тәкъдим ителә ( 20 төшке аш). Социаль туклануга талоннырын алу өчен, гаризә тутырырга һәм аны профкомга кертеп бирергә кирәк.

## Электрон кошелек чыгымнарын компенсацияләү

Әлеге ярдәмне алу өчен, гаризә тутырырга һәм ана транспорт картасына 400 сумнан ким булмаган суммагагы акча салыну турындагы чекны теркәргә кирәк. **Ай саен 140 студент 400 сум күләмендә компенсация ала.** Син дә алар исемлегендә була аласың!

## Материаль ярдәм

Бу төрдәге ярдәм көндезге уку бүлегенең бюджет һәм түләүле формаларында белем алучы түбәндәге категория студентларга бирелә:

- **Тулы булмаган гаиләдән булган студентлар**.
- **Күп балалы гаиләләрдән булган студентлар**.
- **Әти-әнисе пенсионер яки I, II группалы инвалид булган студентлар**.
- **Студент гаиләләре**.
- **Балалар тәрбияләүче студентлар**.
- **Читтән килеп укучы студентлар** (каникуллар вакытында өйгә кайту чыгымнарын компенсацияләү).

Шул ук вакытта материаль ярдәм студентның җитди авырып китүе, якын туганы үлү, шәхси милеген югалту, бала туу очракларында да бирелергә мөмкин.

## Сәламәт тәндә...

...сәламәт акыл, дип юкка гына әйтмиләр. Шуңа күрә һәрвакыт үз сәламәтлегенне кайгыртып тор. Ә уку йортында хезмәт куючы табиблар сиңа ярдәм итәр. Көндезге бүлектә укучы студентлар шәһәр **студентлар хастаханәсендә** (Оренбург тракты, 95 – Универсиада авылы), **КФУның сәламәтлек пунктларында** (мәдәни спорт комплексы, 1 этаж; Г.Кутуй урамында урнашкан 6 номерлы тулак торак) дәвалана ала.

## Санаторий-профилакторий

Әгәр син көндезге түләүсез уку бүлеге студенты икән, димәк син елга бер тапкыр **КФУның санаторий-профилакториенә юллама ала аласың**.

Бирегә: **көнгә өч тапкыр бушлай туклану** (Г.Кутуй ур., 2 б адресы буенча урнашкан студентлар шәһәрчеге һәм КФУның физкорпусы ашханәләрендә).

Гомуми савыгу һәм медицина җиһазлары һәм медикаментларын кулланып, **профильле дәвалану**.
**Ял итү мөмкинлеге**.

## Билен кысып буган, диләр...

«Әллә каян күренеп тора,солдатта булган, диләр», – дип җырлыйлар. Ләкин бу синең турында түгел, чөнки син әлегә студент һәм армиягә бару турында бу берничә ел эчендә онытып торсаң да була. Әгәр инде сиңа Ватан алдындагы бурычыңны үтәргә чакырып хат килгән икән, димәк, син тиешле мәгълүматтан хәбәрдар түгел. Шуңа күрә игътибарлы бул!

I курсның көндезге бүлегендә укучы егетләргә КФУның икенче бүлегендә **мәҗбүри хәрби учетка басарга кирәк булачак**. Учетка басу эше КФУның институт һәм факультет җитәкчелегенә хәбәр ителгән мәгълүматка туры китереп башкарыла. Учетка басу өчен, үзең белән паспорт һәм хәрби-учет документлары – теркәлү турында таныклык яисә хәрби билетны алып килергә кирәк. Учетка баскан кешеләргә яшәү урыны буенча хәрби комиссариатка тәкъдим итү өчен, **справка** бирелә. Әлеге справка сезне уку дәверендә РФнең Кораллы көчләр рәтенә хәрби хезмәткә алуны кичектереп торачак.

2 бүлек адресы: **М.Межлаук ур., 1 йорт** (керү ишек алдыннан, 3 кат, 302 һәм 306 кабинетлар).
Эш вакыты: **дүшәмбе-җомга, 8.00-17.00**, төшке аш вакыты: 12.00-13.00.
Тел.: **292-22-91**




# Укы һәм «хезмәт хакы» ал!

КФУ ҮЗ СТУДЕНТЛАРЫ ӨЧЕН МЕНӘ ДИГӘН МӨМКИНЛЕКЛӘР АЧА! СИН БУ УКУ ЙОРТЫНА КЕРЕП, ЗАМАНЧА ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛГАН АУДИТОРИЯЛӘРДӘ ТАНЫЛГАН ГАЛИМНӘРЕБЕЗДӘН ТӨПЛЕ БЕЛЕМ АЛЫП, КИЛӘЧӘК ТОРМЫШЫҢА НЫКЛЫ НИГЕЗ САЛЫП КЫНА КАЛМАЯЧАКСЫҢ, Ә ЯХШЫ УКЫГАН ҺӘМ ҮЗ ТАЛАНТЛАРЫҢНЫ КҮРСӘТКӘН ӨЧЕН, ГОРУР РӘВЕШТӘ «ХЕЗМӘТ ХАКЫ» ДА АЛАЧАКСЫҢ! ШУЛАЙ ИТЕП, СИН ТҮБӘНДӘГЕ СТИПЕНДИЯЛӘРГӘ ДӘГЪВА КЫЛА АЛАСЫҢ:

✓**РФ Президенты һәм РФ Хөкүмәтенең** махсус дәүләт стипендияләре.

✓**ТРның** махсус стипендиясе.

✓Мәктәп укучылары арасында үткәрелгән бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларда призлы урын алучылар һәм җиңүчеләр өчен **ТР Президенты** стипендиясе.

✓Шәһәр хуҗалыгы, иҗтимагый тармак һәм физика-математика фәннәре өлкәсендә уңышка ирешкән өчен, **Казан шәһәре мэрының** махсус стипендиясе.

✓Уку, фәнни-тикшеренү, җәмәгать эшләрендә, мәдәни-иҗади һәм спорт эшчәнлегендә уңышларга ирешкән өчен, **югары дәүләт академик** стипендиясе.

✓**Оксфорд-Россия хәйрия фонды** стипендиясе.

✓**ТР Фәннәр академиясе** стипендиясе.

✓Урта Азия илләреннән Казан югары уку йортларына укырга килгән татар студентлары өчен, **ТР Фәннәр академиясе** премиясе.

✓Юридик факультет студентлары өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган А.А.Собчак ис. шәхси** стипендия.

✓Әдәби иҗат, политология һәм журналистикада уңышка ирешкән студентлар өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган А.И.Солженицын ис. шәхси** стипендия.

✓Борынгы Рус мәдәнияте һәм әдәбияты белән бәррәттән, филология һәм культурология өлкәләренең фәнни тикшеренүләрендә актив катнашкан студентлар өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган Д.С.Лихачев ис. шәхси** стипендия.

✓Югары академик күрсәткечләргә ия булган икътисад факультетлары студентлары өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган Д.С.Лихачев ис.** һәм **Е.Т.Гайдар ис. шәхси** стипендияләр.

✓**В.Потанин фонды** стипендиясе (ел саен университеттан 20 яхшы студент билгеләнә).

✓Гидрометеорология һәм экология белгечлеге буенча югары курста яхшы билгеләргә генә укучы студентлар өчен, **«Фобос» фонды социаль** стипендиясе.

✓**«Ак Барс» Банк ААҖ** стипендиясе.

✓Бакалавр, магистр һәм аспирантлар өчен, **British Petroleum** стипендиясе.

✓Ислам тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче КФУ студентлары өчен, **«Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифенә ярдәм фонды»** стипендиясе.

! **Онытма:** КФУ студенты булган һәр кешегә 1 сентябрьдән башлап, **1272 сум** күләмендә академик стипендия түләнәчәк. Ә социаль стипендиянең күләме – **1908 сум.**

**Сүз уңаеннан!** Кайбер стипендияләрне хәтта **түләүле бүлектә укучы студентларның да алу мөмкинлеге бар.** Мәсәлән, ТРның махсус стипендиясе; В.Потанин фонды стипендиясе; «Ак Барс» Банк ААҖ стипендиясе.
Әгәр син Бөтенроссия олимпиадаларының призлы урын алучысы яки җиңүчесе икән, КФУга укырга кереп, бер шиксез югары стипендиягә дәгъва кыла аласың. Җиңүчеләр ай саен – **10 мең**, ә призлы урын алучылар **4 мең** күләмендә стипендия алачак.

## Казан шәһәрендә КФУның төп биналары урнашу тәртибе

**КФУ ның төп бинасы,**
*Кремль ур., 18*
**Фундаменталь медицина һәм биология институты, Юридик факультет**

**А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты,**
*Лобачевский ур., 1/29*

**II корпус**
*Кремль ур., 35*
**Экология һәм география институты, Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты, Хисаплау математикасы һәм мәгълумати технологияләр институты,**

**Мәгълумати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе, КФУның «Univer» Медиа-Үзәге**
**Газета редакцияләре: «Казанский университет», «Darelfønyn», Univer-TV**
*Проф.Нужин ур., 1/37*

**УНИКС мәдәни-спорт комплексы**
*Проф.Нужин ур., 2*

**Фундаменталь медицина һәм биология институты**
*К.Маркс ур., 74*

**Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты**
*Товарищеская ур., 5*

**Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты,**
*Кремль ур., 4/5*

**Идарә итү һәм территориаль үсеш институты,**
*Кремль ур., 6/20*

**Физика институты**
*Кремль ур., 16 а*

**Халыкара мөнәсәбәтләр институты**

**Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты,**
*Сул Болак ур., 44*

**Педагогика һәм психология институты,**
*Межлаук ур., 1*

**Филология һәм сәнгать институты,**
*Межлаук ур., 3/45*

**«Мәскәү» спорткомплексы,**
*Мәскәү ур., 49*

**Халыкара мөнәсәбәтләр институты,**
*Пушкин ур., 1/55*

**Фәлсәфә факультеты,**
*Пушкин ур., 1/55*

**Филология һәм сәнгать институты,**
*Татарстан ур., 2*


**Икътисад һәм финанс институты,**
*Бутлеров ур., 4*

**Инженерлык институты,**
*Сәйдәшев ур., 12*

**«Бустан» спорткомплексы, «Бустан» бассейны,**
*Кулагин ур., 8а*

**Универсиада авылы, «Буревестник» бассейны, Теннис академиясе**

Универсиада авылына бару схемасы (47 нче номерлы маршрут)




# Студент сүзлеге

Ничек кенә кызганыч һәм күңелсез булмасын, син инде мәктәп белән саубуллаштың. Университет системасы мәктәпнекеннән нык аерыла. Борчылма, беренче карашка кыенрак кебек тоелса да, бик тиздән син ана күнегерсең! Шулай итеп, монда «сыйныф» дигән төшенчә юк. Укунын башыннан ук студентлар **академик төркемнәргә** бүленә. Ул дуслар һәм танышлар төркеме генә түгел, ә зур университет җәмгыятенең кечкенә ячейкасы да. Ул – үз структуралы деканат, институт һәм факультет кафедралары, Студентлар лигасы, университет бүлекләре белән бәйләнештә торган тулы бер «институт»!

Һәрбер институтның җитәкчесе булган кебек, төркемдә дә шундый кеше була. Ул – **староста**. **Староста** – академик төркемнең формаль башлыгы һәм кайбер административ функцияләрне дә башкаручы студент. Ул – студентлар һәм уку йорты администрациясе арасындагы кеше. Озын сүзнең кыскасы, берәр соравың туса, расписаниене онытсан, аудиторияне белмәсән, хаклы рәвештә старостаннын башын әйләндерә аласың!

Төркемнең «түрәләре» староста белән генә чикләнми, аннан өстенрәк **куратор** вазифасын башкаручы да бар. Куратор итеп, университет укытучысы билгеләнә. Ана һәрвакыт уку, җәмәгать эшләре, мәдәни һәм спорт эшчәнлекләренә бәйле сорауларыңны бирә аласың. Әгәр берәр укытучы яисә университет хезмәткәре белән конфликт, аңлашылмаучанлыклар килеп чыкса, куратор сиңа проблемаларыңны хәл итәргә ярдәм итәр.

2013/14 уку елының 1 семестрына

## Дәресләр тәртибе

8.30 - 9.50
10.00 - 11.20
11.30 - 12.50
13.05 - 14.25
14.40 - 16.00
16.10 - 17.30
17.40 - 19.00
19.10 - 20.30
20.40 - 22.00

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Махсус чыгарылыш
Тираж 1000

Баш мөхәррир – Илдар Азат улы Кәримов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, Л.Х.Исхакова
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: Д.Поварова, А.Галимуллина, Ә.Фазлыйәхмәтов
Номерны әзерләгәндә Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, Г.З.Камалиева идеяләре файдаланылды
Газета бушлай таратыла

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00. «Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317.